ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.02.2022 г. Заинск № 104

**«Зәй муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле буенча планлы тикшерүләр үткәргәндә тикшерү кәгазьләре (контроль мәсьәләләр исемлеге) формаларын раслау турында»**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерү кәгазьләрен (контроль сораулар исемлекләрен) эшләүгә һәм раслауга гомуми таләпләрне раслау турында» 2017 елның 13 февралендәге 177 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты:

## карар бирә:

1. Күпфатирлы йортлар белән идарә итүче юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга карата муниципаль торак контроле буенча планлы тикшерүләр үткәргәндә тикшерү кәгазьләренең (контроль мәсьәләләр исемлекләренең) формаларын (контроль сораулар исемлекләрен) кушымта нигезендә расларга.
2. Планлы тикшерү уздырганда торак законнары үтәлешен тикшерү актына тикшерү кәгазен (контроль сораулар исемлеген) куярга.

3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының zainsk.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2002 елның 1 мартыннан үз көченә керә.
5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Н. Кулагина
(85558) 7-08-18